**Казан шәһәре Башкарма комитетының**

2024 елның 31 маендагы 2259 номерлы карары

# Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 26 маендагы 1314 номерлы «Казан шәһәренең маневрлы муниципаль торак фондын төзү турында»гы карарына үзгәреш кертү хакында

Норматив хокукый актны Россия Федерациясе Торак кодексының 95 статьясындагы 3.1 пунктына туры китерү максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 26 маендагы 1314 номерлы «Казан шәһәренең маневрлы муниципаль торак фондын төзү турында»гы карары (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 26 июнендәге 1781 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) кушымтасындагы 1.3.4 пунктына, «күпфатирлы йортны» сүзләре алдыннан «шул исәптән» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Ә.Гыйниятуллинга йөкләргә.

**Җитәкче Р.Г.Гафаров**